Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Борискино авылы башкарма комитеты

КАРАРЫ

20 октябрь 2022 ел № 16

Әлмәт муниципаль районы Борискино авылы башкарма комитетының 2017 елның 29 декабрендәге 11 номерлы «Әлмәт муниципаль районының Борискино авыл җирлеге кешеләр күпләп була торган торак секторда һәм объектларда янгын-профилактика эшен оештыру турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Янгын куркынычсызлыгы турында»1994 елның 18 ноябрендәге 719 номерлы карары нигезендә

Борискино авылы башкарма комитеты
КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Борискино авылы башкарма комитетының 2017 елның 29 декабрендәге 11 номерлы «Әлмәт муниципаль районының Борискино авыл җирлеге кешеләр күпләп була торган торак секторда һәм объектларда янгын-профилактика эшен оештыру турында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

карарга 1 нче кушымтада:

I бүлекнең 1.3 пункты тугызынчы абзацында «Янгынга каршы пропаганда - җәмгыятькә янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү проблемалары һәм юллары турында максатчан мәгълүмат бирү,» сүзләрен «Янгынга каршы пропаганда - җәмгыятькә янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү юллары турында хәбәр итү,» сүзләренә, «җайланма» сүзен «уздыру» сүзенә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Борискино авылы, Үзәк урам, 61 йорт; Берёзовка бистәсе, Үзәк урам, 16 йорт территориясендә урнашкан махсус стендларда игълан итәргә, шулай ук «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылганнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырым.

Борискино авылы башкарма
комитеты җитәкчесе Ж.С.Илалов